Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

22.07.2021 г. Менделеевск № 76

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
коммерциясез оешма социаль-икътисади
үсешенә ярдәм итү фондын
бетерү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 123.20 ст. 2 өлеше нигезендә, «Коммерциясез оешмалар турында» 12.01.1996 ел, № 7-ФЗ Федераль законга таянып, Россия Федерациясе Граждан кодексының 123.20 ст. 2 өлеше нигезендә,
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы коммерциясез оешма социаль-икътисади үсешенә ярдәм итү фондын бетерергә. Бетерү вакытын 2021 елның 23 августыннан 2022 елның 23 августына кадәр билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә ярдәм итү фонды ликвидаторы итеп Гильманова Альбина Фирдәвес кызын билгеләргә.
3. 2021 нче елның 26 августына кадәр Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә оешманың ликвидация процессында булуы турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен документлар тапшырырга. Җаваплы зат - Гильманова Альбина Фирдәвес кызы.
4. Оешманы бетерү турында хәбәрне «Вестник государственной регистрации» журналында ликвидация процессында оешманың булуы турында мәгълүматлар бердәм дәүләт реестрына кертелгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга (юридик затларның бердәм дәүләт реестрына, оешманың ликвидация процессында булуы турында белешмәләр кертелгәннән соң). Җаваплы зат - Гильманова Альбина Фирдәвес кызы.
5. Кредиторлар белән исәп-хисап ясарга, кирәкле хисапны законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда дәүләт хакимияте органнарына тапшырырга;
6. Ликвидаторга арадаш ликвидация һәм ликвидация балансларын төзергә һәм раслау өчен Президиум фондына тапшырырга;
7. Бетерү процедурасын тәмамлау өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә документларны тапшырырга.

Совет Рәисе В.С.Чершинцев